СОВЕТ САБИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
422060, Республика Татарстан, Сабинский район,
п.г.т. Богатые Сабы, ул. Г.Закирова, 52

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
САБА МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ
422060, Татарстан Республикасы, Саба районы,
Байлар Сабасы ш.т.п., Г.Закиров урамы, 52 йорт

тел. (84362) 2-31-33, 2-31-44, факс (84362) 2-31-74, e-mail: saba@tatar.ru, www.saby.tatarstan.ru

№ 111 от 15.12.2021

на № __от _________

# КАРАР

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Алтын билгесе турында

Саба муниципаль районының иминлеген тәэмин итүгә һәм аның халкының тормыш дәрәҗәсен үстерүгә юнәлдерелгән эшчәнлек өчен , икътисад, сәнәгать, авыл хуҗалыгы һәм терлекчелек, мәдәният һәм сәнгать, мәгариф һәм фән, сәламәтлек саклау, спорт, дәүләтчелек, җирле үзидарә үсешенә аерым шәхси өлеш керткән, район һәм аның халкы алдындагы башка казанышлар өчен гражданнарны бүләкләү максатларында, Саба муниципаль районы Советы КАРАР БИРДЕ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Алтын билгесе турында Нигезләмәне расларга (кушымта итеп бирелә).
2. Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru. рәсми порталында бастырып чыгарырга.

Саба муниципаль
районы Башлыгы — Р.Н. Минниханов

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районы Советының
2021 елның 15 декабрендәге
111 номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының Алтын билгесе турында**
**НИГЕЗЛӘМӘ**

## 1. Гомуми нигезләмәләр.

1.1. Алтын билге Россия Федерациясе гражданнарының икътисадны, җитештерү, социаль өлкә, мәдәният, тәрбия һәм мәгариф, сәламәтлек саклау, спорт һәм физик культура, әйләнә-тирә мохитне саклау, законлылык, хокук тәртибе һәм җәмәгать куркынычсызлыгын үстерү буенча иҗтимагый һәм муниципаль эшчәнлек өлкәсендәге, Саба муниципаль районының абруен һәм дәрәҗәсен арттыруга ярдәм итүче башка эшчәнлек өлкәсендәге зур казанышларын тану йөзеннән тапшырыла.

1.2. Конкрет затны Алтын билге белән бүләкләү район Башлыгы инициативасы белән дә, тиешле учреждение, оешма яки предприятие җитәкчесе тәкъдиме белән дә башкарыла.

1.3. Шәһәр яки район территориясендә даими яшәүче чит ил гражданнарын һәм гражданлыгы булмаган затларны бүләкләүгә тәкъдимнәр гомуми нигезләрдә башкарыла.

1.4. Гражданнарның шәхси мөрәҗәгатьләре буенча бүләкләү башкарылмый.

1.5. Бүләкләү турында тәкъдим бүләкләү планлаштырыла торган датага бер ай кала кертелә.

1.6. Алтын билге белән бүләкләү турындагы карар район Башлыгы карары белән рәсмиләштерелә һәм Саба муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарыла.

1.7. Бүләкләнүчегә Алтын билге тапшыруны район Башлыгы яки ул вәкаләт биргән вазыйфаи зат тантаналы шартларда башкара.

1.8. Алтын билге белән бәйле чараларны матди-техник һәм оештыру ягыннан тәэмин итүне, шулай ук бүләкләнүчеләрне исәпкә алуны район Советы Аппаратының Оештыру Бүлеге гамәлгә ашыра.

1.9. Алтын билге югалган очракта аның дубликаты бирелми.

## 2. Районның Алтын билгесе тасвирламасы.

2.1. Саба муниципаль районының Алтын билгесе, әлеге карарга 1 кушымтада бирелгән эскиз үрнәге нигезендә, 585 пробалы алтыннан ясалган, як үлчәмнәре 13 мм һәм 16 мм булган, Саба муниципаль районы гербы

формасындагы металл планкеткадан гыйбарәт.

2.2. Алтын билгенең алгы ягында Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Гербы сурәтләнгән.

2.3. Алтын билгенең арткы ягында таш кисәкләре - үрмәкүч, ныгытма - цанг белән ныгытыла.

### 3. Мактау грамотасы белән бүләкләү турындагы карарны гамәлдән чыгару

3.1. Саба муниципаль районы Башлыгы бүләкләүдән соң Алтын билгене бүләкләүгә тәкъдимнең дөрес булмавы яисә нигезсез булуы ачыкланган очракта бүләкләү турындагы карарны гамәлдән чыгарырга мөмкин.

3.2. Бүләкләүне гамәлдән чыгару турында карар кабул ителгән затка тапшырылган Алтын билге Саба муниципаль районы Советы аппаратына кайтарылырга тиеш.

### 4. Тапшыру тәртибе

4.1. Алтын билге Саба муниципаль районы Башлыгының бүләкләү турындагы карары басылып чыкканнан соң бер ай вакыт эчендә тапшырылырга тиеш.

4.2. Алтын билге тапшырылмаган бүләкләнүче үлгән очракта, бүләк бүләкләнүченең гаиләсенә тапшырыла.

Татарстан Республикасы Саба
муниципаль районының Алтын
билгесе турындагы Нигезләмәгә
1 кушымта

Эскиз үрнәге

